Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районы
Янил авыл җирлеге Советы

# КАРАР

2020 елның 28 январе | 1 номерлы

Янил авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2013 елның 22 ноябрендәге 32 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә Янил авыл җирлеге карар бирде:

1. «Җир салымы турында» 2013 елның 22 ноябрендәге Янил авыл җирлеге Советының 32 номерлы карарына ( Янил авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 ноябрендәге 42 номерлы, 2015 елның 28 маендагы 25 номерлы, 2015 елның 26 ноябрендәге 16 номерлы, 2017 елның 27 июнендәге 14 номерлы, 2018 елның 9 ноябрендәге 32 номерлы, 2018 елның 29 ноябрендәге 37 номерлы, 2018 елның 20 декабрендәге 39 номерлы, 2019 елның 28 ноябрендәге 26 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) кадастр хакының 0,1% ы – 2017 елның 29 июлендәге «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланылмый торган, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә, шулай ук гомуми кулланылыштагы җир кишәрлекләренә карата;»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: www.pravo.tatarstan.ru, шулай ук Янил авыл җирлеге торак пунктлары территориясендә махсус мәгълүмат стендларында да.

3. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.

Янил авыл
җирлек башлыгы И.Х.Курбанов

ОГРН 1021607753310
ИНН 1623001893